ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясе турында» 2005 елның 26 маендагы 1292-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 5; 2009, № 5; 2012, № 2, № 4, № 6 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (XI өлеш); 2018, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясен түбәндәге составта төзергә:

Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, комиссия рәисе (килешү буенча);

Кадыйров Рөстәм Раиф улы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча);

Яһүдин Шакир Шәяхмәт улы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе, комиссия рәисе урынбасары;

Анфимова Алла Леонидовна – Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары (килешү буенча);

Әхмәтшин Альберт Мәхмүт улы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенең хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек секторы баш киңәшчесе (килешү буенча);

Бутаева Наталья Владимировна – Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары (килешү буенча);

Вәлиев Рамил Миргасыйм улы – «Хәтер китабы» редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе баш мөхәррире (килешү буенча);

Габдрахманова Гөлнара Зәкәрия кызы – Архив эше буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты рәисе (килешү буенча);

Завгороднев Алексей Анатольевич – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары (килешү буенча);

Җәләлиева Әминә Гәрәй кызы – Татарстан Республикасы пенсионерларның һәм инвалидларның – сәяси репрессияләр корбаннарының региональ иҗтимагый-гуманитар оешмасы рәисе (килешү буенча);

Захарова Светлана Михайловна – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе;

Ибәтов Мөхәррәм Мансур улы – Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары (килешү буенча);

Нәбиев Ринат Әхмәтгали улы – тарих фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры (килешү буенча);

Сабурская Сәрия Харис кызы – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча);

Таһиров Индус Ризак улы – тарих фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбе бүлегенең ватан тарихы кафедрасы профессоры (килешү буенча);

Хвостиков Игорь Владимирович – Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча);

Шакиров Илнур Ирек улы – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы (килешү буенча).»;

2) кушымтаның 1 бүлегендәге икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Татарстан Республикасы законнары җыелмасын чыгару буенча республика комиссиясе төзү турында» 2009 елның 5 ноябрендәге 478-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 нче кушымтасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 11; 2012, № 9; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4; 2017, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Татарстан Республикасы законнары җыелмасын чыгару буенча республика комиссиясе составыннан (алга таба әлеге пунктта – комиссия) А.Б. Гревцовны, В.Н. Демидовны, Б.Л. Железновны, Ф.Г. Хөснетдиновны чыгарырга;

2) комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Долгов Марат Шамил улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Скирда Максим Владимировичны – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

3) комиссия рәисе урынбасары Сәфәров Әсгать Әхмәт улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесе – комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

4) комиссия әгъзасы Глухова Лариса Юрьевна вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 2011-VI ДС